ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

15.11.2021　　　　　　　　8

с. Татарское Бурнашево

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылы гражданнар җыенында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2021нче елның 25 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Юматово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- товар белән тәэмин итүче исәп-хисап пунктына кадәр китереп, Юматово авылына юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Халык җыенын Юматово авылы, Заречная урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан чиркәү бинасы янында үткәрергә.

4. Халык җыенын Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　С. В. Бурукин